# Ятып калганчы, атып кал

**Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Казанның 18нче сырхауханәсендә коронавируска каршы прививка ясатты.**

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты **Әзһәр Шакиров** 82нче яше белән бара. Аның фикеренчә, вирусны үзеңә дә, башкаларга да йоктырмас өчен прививка бик кирәк.

– Театрда шактый кеше прививка ясатты. Барысы да яхшы булыр дип өметләнәбез. Без кешеләр белән аралашабыз бит, өйдә генә ятмыйбыз, шуңа күрә ясатырга кирәк дип уйлыйм. Үзеңне уйламасаң, башкалар турында булса да кайгыртырга кирәк. Әгәр безнең вакцина начар икән, аны чит илләр сатып алмас иде, – диде артист.

Әле бер ел элек кенә, шушы зәхмәт тарала башлаганда, ул башта бу вирусның барлыгына ышанмаган, якын туганы вафат булганнан соң тына фикере үзгәргән. «Бәлки, кемнәрдер прививканы кирәксез дип уйлыйдыр, ләкин «ятып калганчы, атып кал», диләр бит. Авырып ятарга язмасын. Мөмкин кадәр сакланырга кирәк. Бу зәхмәтнең кайчан бетәсе дә билгесез. Булачак инде ул, грипп кебек ел саен киләчәк», – дип саный Әзһәр Шакиров.



Табиб-эпидемиолог Ландыш Каһирова 18нче сырхауханәдә вакцинация өчен барлык шартлар да тудырылуын әйтте. 3 меңнән артык кешегә прививка ясаганнар инде.

Артист сәламәтлекне ныгыту өчен физик күнегүләр дә ясаганын әйтте. Соңгы елларда диңгезгә бармаса да, шифаханәләргә йөреп тора икән.

Татарстанның атказанган артисткасы, 54 яшьлек **Мәрьям Йосыпова** коронавирус белән авырмаганын әйтте.

– Бер дә авырыйсым килми, шуңа вакцинация кирәктер дип ышанып килдем. Безнең вакцинаны ышанычлы дип сөйлиләр. Халыкта төрле сүзләр йөри, әле җентекләп өйрәнелмәгән диләр. Ул сүзләргә карап тормадым, мин аңа ышанам, – дип сөйләде ул.

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы **Наилә Гәрәева,** үзе авырмаса да, якыннары бу чирне йоктырган.

– Улым, 27 яшьлек оныгым авырды. Без кешеләр белән аралашмаска тырышабыз. Ишектән генә берәр нәрсә тапшырып китәләр. Инде ярты елдан артык беркем белән дә күрешмәскә тырышам. Әмма гел изоляциядә яшәү дә туйдырды. Күп артистлар катнаша торган спектакльләрдән дә өлкәннәрне алдылар. Әле март аенда гына уйнарга рөхсәт итә башладылар. Алайса, соңгы өч айда бөтенләй уйнаган юк иде. Прививка ясатыргамы-юкмы дип икеләнеп йөргәндә, улым: «Кирәк, әни», – диде. Куркып яшәгәнче, ясатыйм әле, дидем. Кешеләргә дә шуны киңәш итәм. 80 яшьтә мин дә ясаткач, кешеләргә киңәш итәргә хакым бар дип уйлыйм. Бу вирус тизрәк бетсен иде инде, – дигән теләген җиткерде Наилә апа.

Артистларга прививкадан соң сакланырга, салкын тидермәскә тырышырга киңәш иттеләр.

Рухият

## Изге ай якынлаша

**Татарстан Диния нәзарәтенең Голәмәләр һәм Казыйлар шуралары утырышында 2021 елда Рамазан-шәриф аен үткәрү белән бәйле мәсьәләләр буенча карарлар чыгарылды.**

Хәзрәтләр Рамазан ае башлану һәм тәмамлану вакытын, тәравих намазында укыла торган рәкәгатьләр санын, фидия һәм фитыр сәдакасы күләмен билгеләде.

ТР Диния нәзарәте хәбәр иткәнчә, быел 13 апрельдә - уразаның беренче көне, 12 майда – уразаның соңгы көне. 12 апрельдә беренче тәравих намазы укыла, 13 майда Ураза бәйрәме була. Тәравих намазы 20 рәкәгать укыла.

Рамазан аенда фитыр сәдакасы һәм зәкят билгеләнә. Зәкят түләү өчен нисабның күләме 310 мең сум (алтын буенча) тәшкил итәчәк.

Фитыр сәдакасы түләү өчен нисаб күләме – 36 мең сум (көмеш буенча), фитыр сәдакасы күләме (зәкят әл-фитыр – Ураза тәмамлану уңаеннан бирелә торган сәдака) арпа белән исәпләгәндә – 100, йөзем буенча – 700 сум.

Фитыр сәдакасы бирү һәр мөселман өчен ваҗиб гамәлләрдән санала. Ул мохтаҗларга бирелә. Фитыр сәдакасын, мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бөтен кеше дә бирергә тиеш.

Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үз кеременнән түли. Ир бала балигъ булгач, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ир-атлар җилкәсенә төшә.

Моннан тыш, сәламәтлегенә бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлеге булмаган һәм аны башка вакытта да каза кылып үти алмаучыларга тотылмый калган һәрбер көн өчен 200 сум күләмендә фидия билгеләнде. Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен каралган сәдака. Ул акчалата бирелергә мөмкин.

Кулланучы хәбәрләре

# «Могҗизалы чара» һәм башка алдавычлар турында

**Гаммәви мәгълүмат чараларында, шул исәптән интернет челтәрендә дә, пандемиягә бәйле рәвештә гражданнарны алдау һәм җиңел генә табыш алу максатыннан төрледән-төрле схемалардан файдаланучы мошенниклар пәйда булды.**

1. Һава чистарткыч яки башка төрле «могҗизалы чара» сатып алырга тәкъдим итүчеләр бар. Алар, янәсе, һаваны вирустан арындыра һәм коронавирус инфекциясе йоктырудан саклый. Кагыйдә буларак, сезгә шактый кыйммәт бәягә гадәти һава дымландыргыч яки фильтрлы медицина битлеге сатарга телиләр. Ә өстәмә битләрне «могҗизалы чара»ның документы буларак тәкъдим итәләр, аларны мошенниклар гадәти принтерда чыгартып ала.
2. Коронавирустан азык өстәмәләре яки дарулар сатып алырга тәкъдим итәргә мөмкиннәр. «Тылсымлы прибор» яки «могҗизалы дару» сатып алырга үгетләгән адәмнәр белән элемтәгә кермәгез. Шуны исегездә тотыгыз: даруларны бары тик табиб кына билгели һәм аларны мөстәкыйль рәвештә яки чит кешеләр киңәше белән кабул итмәвең хәерле.
3. Алдан түләү шарты белән танылган һәм ышанычлы җитештерүчеләрнең шәхси саклану чараларын сатып алырга киңәш итәләр. Әмма акча алганнан соң товарны китермиләр.
4. Вирус йөртүче кеше белән аралашуыгыз турында мәгълүмат белән һәм өйдә түләүле анализ үткәрүне таләп итеп шалтырataлар. Аларның берсенә дә акча күчермәгез һәм шәхси мәгълүматларыгызны бирмәгез! Түләүле лабораторияләр сез сораган очракта гына анализ үткәрә ала, алар хакында бөтен мәгълүматны сайтлардан һәм башка ачык чыганаклардан белергә мөмкин.
5. Чынлыкта булмаган дәүләт ярдәме күрсәтү, компенсация тәкъдим итү өчен шәхси мәгълүматлар сорыйлар. Дәүләт хезмәте вәкилләре мондый мәгълүматны телефон аша сорамый һәм фатирдан фатирга йөрми!
6. Өйдә бушлай тест, коронавируска каршы вакцинация узарга яки фатирга дезинфекция үткәрергә тәкъдим итәләр. Кагыйдә буларак, моның максаты – фатир басу. Чит кешеләргә беркайчан да ишек ачмагыз! Бары тик Роспотребнадзор, Сәламәтлек саклау министрлыгы, Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы, Хөкүмәт сайтлары һәм Дәүләт хезмәтләре порталында гына ышанычлы һәм дөрес мәгълүмат табарга мөмкин.

# МОШЕННИКЛАР тозагына эләкмәгез

Өйдә су фильтрлары сату турында.

**ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы "кайнар линиясе" телефонына өйгә килеп су фильтрлары сатучылар турында залапып шалтырату очраклары ешайган. Мошенниклар, суга экспресс-тест үткәрү кебек ялган технологияләрдән файдаланып, нигездә, өлкән яшьтәге кешеләрне тәп башына утырта.**



Территориаль орган белгечләре гражданнарга өйдә товар сатып алганда бик тә сак булырга һәм килешү төзегән вакытта аның шартлары белән җентекләп танышырга киңәш итә. Әйбер сатып алыр алдыннан:

- ✔ товарның инструкциясен (паспортын) өйрәнегез,
- ✔ сертификатлаштыру органы тарафыннан расланган тәңгәллек сертификатын таләп итегез,
- ✔ сатып алырга ниятләгән әйберенең максатка ярашлылыгын һәм кирәге чыгачакмы-юкмы икәнен яхшылап уйлагыз,
- ✔ гаилә әгъзалары белән киңәшегез.

1992 елның 7 февралендә кабул ителгән «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы (№2300 – 1) РФ законының 25 маддәсе 1 пункты нигезендә, кулланучы аңа азык-төлек булмаган товарны тапшырганчыга кадәр 14 көн эчендә, товар файдаланудa булмаган, куллану үзлекләре сакланган һәм аның әлеге сатучыдан алынуына дәлилләр булган очракта, тиешле сыйфатка ия товарны кире кайтарып бирергә хокуклы.

Су чистарту системасы РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 31 декабрендәге 2463нче карары белән расланган, алыштырылырга һәм кире кайтарылырга тиешле азык-төлек булмаган товарлар исемлегенә керми. Ягъни фильтр су белән тәэмин итү системасына тоташтырылган очракта аны кайтарып бирү һәм алыштыру мөмкин түгел.

**Хөрмәтле кулланучылар! Өйгә килеп сатучылардан товар алганда бик тә игътибарлы булыгыз, алга таба суд юлын таптарга һәм башка инстанцияләргә мөрәҗәгать итәргә туры килмәсен өчен бәйләнчек сатучыларның тозагына эләкмәгез.**

**ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы**